**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Ключевая, дом 15, село Новое Ильмово,
Черемшанский район, РТ, 423118

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА ЭЛМӘЛЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Чишмә урамы, 15 нче йорт, Яңа Элмәле авылы,
Чирмешән районы, РТ, 423118

Телефон: (84396) 2-45-51, факс: (84396) 2-45-51 email:
Nilm.Cmn2@tatar.ru

№113 18.12.2023 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 февралендәге № 67 «Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге № 286-ФЗ Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 февралендәге № 67 «Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына (Советның 2018 елның 21 декабрендәге № 109, 2021 елның 30 сентябрендәге № 38, 2021 елның 20 декабрендәге №47, 2023 елның 13 мартындагы № 86 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «үз карамагындагы муниципаль хезмәткәрдә шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;».

1.2. 2.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәтенең кадрлар бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М.Җамалтдинов